КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 декабрь г.Казань № 1109

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомо-биль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү методикасын раслау һәм аның максималь күләмен билгеләү турында» 2024 ел, 26 апрель, 279 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомо-биль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү методикасын раслау һәм аның максималь күләмен билгеләү турында» 2024 ел, 26 апрель, 279 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 7 пункты һәм «Татарстан Республи-

касында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү методикасында 1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү методикасы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 7 пункты һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә эшләнде.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин